РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШИКШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422053, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Шикши,ул.Школьная, д.4
тел.8 (84362) 46-1-35

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЕКШЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422053, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шекше авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт
тел.8 (84362) 46-1-35

e-mail: shik.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
29.06.2020

КАРАР
№ 19

Шекше авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 25 апрелендәге 19 номерлы «Муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында

Район прокуратурасының 2020 елның 19 июнендәге 02-08-02-73-2020 номерлы протесты һәм "Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 2 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль Законы нигезендә Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Шекше авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 25 апрелендәге 19 номерлы «Муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында"карары белән расланган муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

   1.1. 3.1 пунктын киләсе эчтәлектәге 3.1.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

   «3.1.1. Планлы тикшерүнең еллык планына планлы тикшерүләрне кертү өчен нигез булып кабул иткән коннән бер ел үткәннән соң кертелә:

   - дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган уведомлениегә туры китереп, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау;
   - социаль файдаланудагы беренче наемга алынган торак йортның муниципаль реестрында, торак урыннарны наймлаучы булып торучы,

эшчәнлеге тикшерелергә тиешле зат булган Социаль файдаланудагы наемга алынган йортларның муниципаль реестрында исәпкә кую;

- юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата соңгы планлы тикшерүне үткәрү тәмамлануы;
- коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларын билгеләү һәм үзгәртү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/shikshi адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Шекше авыл
җирлеге башлыгы Р.Р. Хайртдинов